| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 октябрь 2021 ел № 6957

Башкарма комитетның «Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларның түләүсез туклануын оештыру чаралары турында» 2021 елның 27 августындагы 5720 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2020 елның 15 декабрендәге 3/3 номерлы карары нигезендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның тулы кыйммәтле балансл ы туклануын тәэмин итү һәм өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларның түләүсез туклануын оештыру чаралары турында» 2021 елның 27 августындагы 5720 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 4 пунктча өстәргә:

«4) муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында адаптацияләнгән белем бирү программасы буенча белем алучы сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен түләүсез кайнар ризык:

- 1-4 сыйныф укучылары өчен – икенче тапкыр түләүсез кайнар ризык;
- 5-11 сыйныф укучылары өчен – ике тапкыр кайнар ризык.»;

2) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында каралган чыгымнарны финанслауны 2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Гаиләне һәм балачакны саклау» 10.04 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 35 192 095 сум (утыз биш миллион бер йөз туксан ике мең туксан биш) сум, шул исәптән 03.1.03.05110 максатчан статья буенча 31 900 471 (утыз бер миллион тугыз йөз мең дүрт йөз җитмеш бер сум) һәм

03.1.02.25510 максатчан статья буенча 4 301 104 (дүрт миллион өч йөз бер мең бер йөз дүрт сум) күләмендә, 2 нче, 3 нче, 4 нче кушымталарда каралганча расларга.»;

3) 1 нче кушымтада:

- 1 пунктның 3 пунктчасына түбәндәге эчтәлектәге 4 пунктча өстәргә:

«4) муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында адаптацияләнгән белем бирү программасы буенча белем алучы сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен түләүсез кайнар ризык:

- 1-4 сыйныф укучылары өчен – икенче тапкыр түләүсез кайнар ризык;

- 5-11 сыйныф укучылары өчен – ике тапкыр кайнар ризык.»;

- 4 пунктчаны 5 пунктча дип санарга;

- 4 пунктның 3 пунктчасына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«- психологик-медицина-педагогик комиссия бәяләмәсе.».

4) кушымтада каралганча 4 нче кушымта өстәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 22 октябрендәге
6957 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2021 елның 27 августындагы
5720 номерлы карарына
4 нче кушымта

Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында адаптацияләнгән белем бирү программасы буенча белем алучы сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны тукландыруны оештыруга чыгымнар
сметасы

| Сыйныф | Балаларның гомуми саны | Көнгә уртача туклану бәясе (сум) | Көннәрнең гомуми саны | Барлыгы (сум) | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Муниципаль бюджет (сум) | Субвенция (сум) |
| 1-4 | 160 | 40,19 | 50 | 321 520 | 321 520 | |
| 5-11 | 147 | 93,60 | 50 | 687 960 | 629 160 | 58 800 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева